РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» ноябрь 2025г. г. Альметьевск №13

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2025 елның 7 маендагы 362 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 03 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2025 елның 7 маендагы 362 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районындамуниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарага кушымтада 2 бүлекнең 2.5. пунктын «Муниципаль хезмәт вазыйфалары» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә:

а) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата:

- югары белем булу-вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфалардан тыш;

- авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу;

б) муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

- муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча – бер елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы;

- муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча – бер елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажы.

Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы, өлкән һәм кече төркем вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына квалификация таләпләре билгеләнми.

2028 елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль хокукый актлар белән каралырга мөмкин муниципаль хезмәтнең өлкән һәм (яки) кече төркем вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә квалификация таләпләре куелмый (урта гомуми белем булганда), әгәр тиешле муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларга 2015 елның 25 апрелендәге 33-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклау пунктлары турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу кертелсә.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Туманова Г.П.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Г.М. Хәбутдинова

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»